ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

Постановление | Карар

2019 елның 7 нче июле | Чистай шәһәре | № 337

Чистай муниципаль районының
гомуми белем бирү оешмаларында
2019-2020 уку елының I яртыеллыгында
укучыларны тукландыруны оештыру турында

“Россия Федерациясендә мәгариф турында”гы 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “2019 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында”гы 10.09.2018 ел, №767 карарын, СанПиН 2.4.2821-10 “Гомуми белем бирү оешмаларында шартларга һәм укытуны оештыруга карата санитар – эпидемиологик таләпләр” Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының 29.12.2010 ел, № 189 карары белән расланган, халыкка социаль ярдәм күрсәтү һәм укучыларның сәламәтлеген ныгыту максатыннан, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

Карар бирә:

1. “Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе” муниципаль казна учреждениесенә (О. В. Купцовага):

1.1. шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны субсидия хисабына тукландыруны оештырырга (көн саен 7 сум 40 тиен);

1.2. укучыларның туклануын оештыруга муниципаль заказны урнаштырганда заказчы булырга кирәк;

1.3. социаль ярдәмгә мохтаж 830 укучы өчен, яшь төркемнәре буенча дифференциацияләнгән кайнар туклануны оештырып, льготалы туклануны күздә тотарга. 7-11 яшьләрдәге 425 укучы өчен-бер укучыга көн саен 30 сум исәбеннән, 11 һәм аннан өлкәнрәк яштәге 405 укучы өчен-бер укучыга көн саен 35 сум исәбеннән;

1.4. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм күләм буенча һәм ЕГИССО (алга таба – ЕГИССО) операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә, укучыларны тукландыруны оештырганда ташламалар бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итү.

Ташламалар турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм күләм, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматлар нигезендә БДИдан файдалану юлы белән алынырга мөмкин.

2. Чистай муниципаль районы Финанс-бюджет палатасына (Н.А. Карманова) туклануны үз вакытында финанслауны һәм акчаларның максатчан кулланылышын тикшереп торуны тәэмин итәргә.

3. Мәктәп ашханәләрен һәм үзләре житештергән азык-төлек товарлары һәм буфетларны тәэмин итүче предприятиеләргә һәм шәхси эшмәкәрләргә муниципаль контрактлар һәм килешүләр

шартларын үтәргә, азык-төлек товарларының һәм әзер ризыкларның сыйфатын һәм куркынычсызлыгын раслаучы документларны вакытында тапшырырга тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең мәгариф буенча урынбасары – Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе башлыгы О. В. Купцованы йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы

Башкарма комитетының
2019 елның 1 июлендәге
337 нче номерлы карарына
Кушымта

,

Яшь категорияләре буенча ташламалы туклану белән тәэмит ителгән укучылар саны

| | Гомуми белем бирү оешмасы исеме | 7 яшьтән алып 11 яшькә кадәр льготалы туклану белән тәэмин ителгән укучылар саны | 11 яшьтән алып һәм өлкән яшьтәге льготалы туклану белән тәэмин ителгән укучылар саны | Льготалы туклану белән тәэмин ителгән укучылар саны |
|---|---|---|---|---|
| 1 | МББУ «1 нче лицей » | - | 8 | 8 |
| 2 | МББУ «1 нче гимназия» | 6 | 3 | 9 |
| 3 | МББУ «2 нче гимназия» | 63 | 20 | 83 |
| 4 | МББУ «3 нче гимназия» | 57 | 92 | 149 |
| 5 | МББУ “1 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” | 50 | 30 | 80 |
| 6 | МББУ “4 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” | 62 | 50 | 112 |
| 7 | МББУ “6 НЧЕ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” | 26 | 25 | 51 |
| 8 | МББУ “5 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” | 40 | 84 | 124 |
| 9 | МББУ “16 НЧЕ УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ” | 55 | 35 | 90 |
| Чистай шәһәре мәктәпләре буенча барлыгы | | 359 | 347 | 706 |
| 1 | МББУ «Гаделша урта мәктәбе» | - | - | - |
| 2 | МББУ «Александровка төп гомуми белем бирү мәктәбе» | 8 | 3 | 11 |
| 3 | МББУ «Луч урта мәктәбе» | 8 | 8 | 16 |
| 4 | МББУ «Каргалы гимназиясе» | 11 | 17 | 28 |
| 5 | МББУ «Яуширмә урта мәктәбе» | 2 | 2 | 4 |
| 6 | МББУ «Кубас төп гомуми белем бирү мәктәбе» | 4 | 4 | 8 |
| 7 | МББУ «Мөслим урта мәктәбе» | - | - | - |
| 8 | МББУ «Түбән Кондрата төп гомуми белем бирү мәктәбе» | - | - | - |
| 9 | МББУ «Иске Роман урта мәктәбе» | 2 | 2 | 4 |
| 10 | МББУ «Татар Баганалысы урта мәктәбе» | - | - | - |
| 11 | МББУ «Татар Талкышы урта мәктәбе» | 4 | 4 | 8 |
| 12 | МББУ «Татар Сарсазы төп гомуми белем бирү мәктәбе» | 1 | 1 | 2 |
| 13 | МББУ «Чуаш Ялтаны  урта мәктәбе” | 3 | 2 | 5 |
| 14 | МББУ «Чистай Выселкасы урта мәктәбе» | 12 | 7 | 19 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 15 | МББУ «Йолдыз урта мәктәбе» | 8 | 5 | 13 |
| 16 | МББУ «Югары Кондрата төп гомуми белем бирү мәктәбе» | 2 | - | 2 |
| 17 | МББУ «Данауровка башлангыч мәктәбе» | 1 | - | 1 |
| 18 | МББУ «Кызыр яр төп гомуми белем бирү мәктәбе» | - | 3 | 3 |
| Авыл гомуми белем бирү оешмалары буенча барлыгы | | 66 | 58 | 124 |
| Барлыгы | | 425 | 405 | 830 |